**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**«28» нче июнь 2021 ел** **№ 91**

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында

Территорияне тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру, шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен җайга салу, «Шәпше авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә нәтиҗәле һәм тәртипкә салынган җирдән файдалануны һәм төзелешне тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы, Шәпше авыл җирлегенең гавами тыңлаулары нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Шәпше авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин